РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Масягутовского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Дружба, д. 12, Азнакаевский район,
с.Масягутово, 423321,
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге
башлыгы

Дружба ур., 12 йорт, Азнакай районы, Мәсгут
авылы, 423321
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» март 2023 ел №1

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге
Советының «2022 елда Азнакай муниципаль
районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты
үтәлеше турында» карары проекты
буенча ачык тыңлаулар билгеләү
турында»

Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге халкының Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Советының «2022 елда Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатларында 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Советының 2012 елның 19 апрелендәге 50 номерлы карары белән расланган Мәсгут авыл җирлегенең гавами тыңлауларын оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә белән карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Советының «2022 елда Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык тыңлауларын үткәрү инициаторы булып Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты – 10 апрель 2023 ел 10 сәг.;

- уздыру урыны – Мәсгут авылы мәдәният йорты;

- язма тәкъдимнәр һәм фикер алышу мәсьәләсе буенча кисәтүләр тәкъдим итәлергә мөмкин булган адрес: 423321, ТР, Азнакай районы, Мәсгут авылы, Дружба урамы, 12 нче йорт.

4. Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Советының «2022 елда Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карар нигезендә билгеләнгән срокларда тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Советының «2022 елда Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында» карары проектын Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге веб-адрес буенча рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatarstan.ru. 2023 елның 16 мартыннан да соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Мәсгут авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http//aznakayevo.tatar.ru// 2023 елның 16 мартыннан да соңга калмыйча игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге башлыгы Д.З.Миннеханов